КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 19 май г.Казань № 333

2025 елга «Татарстан Республикасында физика, математика, информатика педагогларына ярдәм» гранты турында

Физика-математика белеме бирү сыйфатын яхшыртуга, белем алучыларның физик-математик сәләтләрен үстерүгә, Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларының педагог хезмәткәрләренә ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән «Физик-математик алгарыш» проектын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елга «Татарстан Республикасында физика, математика, информатика педагогларына ярдәм» грантын гамәлгә куярга.
2. Бу карарга теркәлгән 2025 елга «Татарстан Республикасында физика, математика, информатика педагогларына ярдәм» гранты турындагы нигезләмәне расларга.
3. Бу карар нигезендә 2025 елга «Татарстан Республикасында физика, математика, информатика педагогларына ярдәм» грантын түләү өчен чыгымнар «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2024 елның 28 ноябрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында әлеге максатлар өчен «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы» ведомствосы буенча каралган акча исәбеннән башкарыла дип билгеләргә.
4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 19 май, 333 нче
карары белән расланды

2025 елга «Татарстан Республикасында физика, математика,
информатика педагогларына ярдәм» гранты турында
нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының «Физик-математик алгарыш» проекты чараларын гамәлгә ашыруда катнашучы педагогларын кызыксындыру һәм аларга ярдәм күрсәтү максатларында 2025 елга «Татарстан Республикасында физика, математика, информатика педагогларына ярдәм» грантын (алга таба – грант) бирү шартларын һәм тәртибен билгели.

2. Грант бирү «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2024 елның 28 ноябрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы» ведомствосы буенча каралган бюджет ассигнованиеләре һәм әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында билгеләнгән максатлар өчен бюджет акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Әлеге Нигезләмәдә аннан файдалану максатлары өчен түбәндәге терминнар кулланыла:

грант алырга теләүчеләр – Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт яисә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында «физика», «математика», «информатика» предметлары буенча гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы педагогик хезмәткәрләр;

грант алучы – грант алу өчен конкурс нигезендә сайлап алу (алга таба – сайлап алу) йомгаклары буенча грант бирү турында карар кабул ителгән грант алырга теләүче;

эш бирүче – Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, хезмәткәре төзелгән хезмәт шартнамәсе буенча грант алган дәүләт яисә муниципаль гомуми белем бирү оешмасы;

индивидуаль белем бирү проекты – «Физик-математик алгарыш» проектын гамәлгә ашыру кысаларында «физика», «математика», «информатика» предметларын тирәнтен өйрәнүгә юнәлдерелгән проект;

мотивацияле хат – грант алырга теләүченең «Физик-математик алгарыш» проекты чараларын гамәлгә ашыруга кертә алган шәхси өлешенә аерым игътибар итеп, «физика», «математика», «информатика» предметларын укыту мәсьәләләре һәм аларны үстерү перспективалары тасвирланган хат (500 сүздән 700 сүзгә кадәр);

портфолио – грант алырга теләүченең соңгы өч уку елында педагогик тәҗрибәсе турында белешмә бирелгән документ.

4. Грант алырга теләүчеләрнең категорияләре:

сайлап алуда катнашуга заявка (алга таба – заявка) бирү датасына карата беренче яисә югары квалификация категориясе һәм биш елдан артык эш стажы булган грант алырга теләүчеләр;

заявка бирү датасына карата биш елга кадәр эш стажы булган грант алырга теләүчеләр;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт яисә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының 5 – 7 нче сыйныфларында белем алучылар өчен «физика», «математика», «информатика» предметлары буенча өстәмә уку курсларын гамәлгә ашыруны тәэмин итүче грант алырга теләүчеләр.

5. Грант түбәндәге номинацияләр буенча грант алучыга бер тапкыр бирелә:

«Физика-математика профиле укытучысы» – 300,0әр мең сумнан иң күбе 100 грант;

«Физика-математика профилендәге яшь укытучы» – 240,0ар мең сумнан иң күбе 150 грант;

«Педагог – физика-математика түгәрәге җитәкчесе» – 90,0шар мең сумнан иң күбе 100 грант.

6. Грант бирү шартлары:

Министрлык тарафыннан оештырыла торган сайлап алуда җиңү;

«укытучы» вазыйфасында хезмәт педагогик эшчәнлеген төп эш урыны буенча кимендә бер тариф ставкасы яисә берьюлы ике вазыйфада эшләү буенча кимендә 0,5 тариф ставкасы күләмендә гамәлгә ашыру;

грант алырга теләүченең белем алу турындагы һәм (яисә) квалификация турындагы документы эш бирүчедә укытыла торган укыту предметына һәм аның педагогик эшчәнлеге профиленә туры килү;

индивидуаль белем бирү проектын бер уку елы дәвамында гамәлгә ашыру;

индивидуаль белем бирү проектын гамәлгә ашыру срогы дәвамында эш бирүчедә хезмәт педагогик эшчәнлеген гамәлгә ашыру.

7. Грант бирү нәтиҗәләре:

«Физика-математика профиле укытучысы» номинациясе буенча:

2025 – 2026 уку елының бердәм дәүләт имтиханы һәм төп дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча «физика», «математика», «информатика» предметлары буенча 2025 – 2026 уку елына минималь билгеләнгән үтү баллын үтмәгән белем алучылар булмау;

2025 – 2026 уку елында «физика», «математика», «информатика» предметлары буенча Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының муниципаль һәм (яисә) республика этапларында приз алучылар яисә җиңүчеләр дип танылган белем алучылар булу;

«физика», «математика» (профильле дәрәҗә), «информатика» предметлары буенча бердәм дәүләт имтиханын 80 баллга һәм аннан югарырак тапшырган кимендә ике белем алучы булу;

«физика», «математика» предметларын тирәнтен өйрәнү программалары буенча укыган, төп дәүләт имтиханында «физика», «математика» предметлары буенча «бишле» билгесе алган 9 нчы сыйныф чыгарылыш укучылары кимендә 10 процент булу;

физика-математика юнәлешендәге инновацион педагогик тәҗрибәне таратуга юнәлдерелгән кимендә ике чара үткәрү;

«Физика-математика профилендәге яшь укытучы» номинациясе буенча:

2025 – 2026 уку елының бердәм дәүләт имтиханы һәм төп дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча «физика», «математика», «информатика» предметлары буенча 2025 – 2026 уку елына минималь билгеләнгән үтү баллын үтмәгән белем алучылар булмау;

2025 – 2026 уку елында «физика», «математика», «информатика» предметлары буенча Республлика мәктәп укучылары олимпиадасының муниципаль этабында приз алучылар яисә җиңүчеләр дип танылган белем алучылар булу;

мәктәп дәрәҗәсендә белем алучылар өчен физика-математика юнәлешендә кимендә ике чара (өстәмә уку курслары, барулар, конференцияләр, конкурслар, фестивальләр һәм башка чаралар) үткәрү;

«Педагог – физика-математика түгәрәге җитәкчесе» номинациясе буенча:

2025 – 2026 уку елының бердәм дәүләт имтиханы һәм төп дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча «физика», «математика», «информатика» предметлары буенча 2025 – 2026 уку елына минималь билгеләнгән үтү баллын үтмәгән белем алучылар булмау;

2025 – 2026 уку елында «физика», «математика», «информатика» предметлары буенча Республлика мәктәп укучылары олимпиадасының муниципаль этабында приз алучылар яисә җиңүчеләр дип танылган белем алучылар булу;

мәктәп дәрәҗәсендә белем алучылар өчен физика-математика юнәлеш ендә кимендә ике чара (өстәмә уку курслары, барулар, конференцияләр, конкурслар, фестивальләр һәм башка чаралар) үткәрү;

физика-математика юнәлешендә инновацион педагогик тәҗрибәне таратуга юнәлдерелгән кимендә ике чара үткәрү.

Грант бирү нәтиҗәләренә грант алучы 2026 елның 1 сентябренә кадәр ирешергә тиеш.

8. Заявканы карап тикшерү һәм грант бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү датасына карата грант алырга теләүче туры килергә тиешле таләпләр:

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган физик затлар исемлегендә тормый;

БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле физик затлар исемлегендә тормый;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында билгеләнгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмый;

бердәм салым исәбендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычы булмый яисә

Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмый.

9.Заявкалар кабул итү сроклары, заявкаларны кабул итүне һәм теркәүне гамәлгә ашыручы оператор (алга таба – оператор) турында белешмә, сайлап алуны уздыру тәртибе һәм сроклары, портфолионы бәяләү критерийлары, грант алырга теләүчеләрнең мотивацияле хаты һәм индивидуаль белем бирү проекты, заявканың формасы, тасвирламасы бирелгән индивидуаль белем бирү проектының формасы, грант алырга теләүченең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы формасы, Министрлык, грант алучы һәм эш бирүче арасында төзелә торган килешү формасы Министрлыкның боерыгы (алга таба – сайлап алу турында боерык) белән раслана.

Заявкаларны кабул итү һәм теркәү өчен Министрлык үз ведомствосы буйсынуындагы оешмалар арасыннан операторны билгели.

10. Министрлык «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Министрлыкның рәсми сайтында (алга таба – рәсми сайт) түбәндәгеләрне бастырып чыгаруны тәэмин итә:

заявкалар кабул ителә башлау датасына кадәр 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, заявкалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы, оператор турында белешмә, заявка составында тапшырыла торган документлар исемлеге белән заявка формасы, заявкалар бирү адресы һәм ысулы, шулай ук Министрлык сайтында урнаштырылган сайлап алу турындагы боерыкка сылтама бирелергә тиешле сайлап алуны үткәрү турында белдерү;

заявкалар кабул ителә башлау датасына кадәр кимендә 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, сайлап алу турында боерык;

расланган датасыннан өч эш көне эчендә грант алу өчен конкурс комиссиясе беркетмәсе (алга таба шул ук эзлеклелектә – конкурс комиссиясе, конкурс комиссиясе беркетмәсе) нигезендә грант бирү турында йә грант бирүдән баш тарту турында карарны раслау хакында Министрлык боерыгы.

11. Сайлап алуда катнашу өчен грант алырга теләүчеләр операторга Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча заявка һәм заявка составында түбәндәге документларны тапшыра:

Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча тасвирлама белән индивидуаль белем бирү проекты;

Россия Федерациясе гражданы паспорты күчермәсе;

эш бирүче яисә эш бирүченең башка вәкаләтле заты тарафыннан таныкланган белем һәм (яисә) квалификация турында диплом күчермәсе;

эш бирүченең җитәкчесе яисә эш бирүченең башка вәкаләтле заты тарафыннан таныкланган хезмәт кенәгәсе күчермәсе яисә грант алырга теләүченең мәҗбүри пенсия иминияте һәм мәҗбүри социаль иминият системаларында индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә алынган грант алырга теләүченең хезмәт эшчәнлеге һәм хезмәт стажы турында белешмә;

Министрлык боерыгыннан квалификация категориясе булуны раслый торган өземтә («Физика-математика профиле укытучысы» номинациясендә грант алырга теләүчеләр өчен);

грант алырга теләүче тарафыннан «укытучы» вазыйфасында хезмәт педагогик эшчәнлеген төп эш урыны буенча кимендә бер тариф ставкасы яисә берьюлы ике

вазыйфада эшләү буенча кимендә 0,5 тариф ставкасы күләмендә гамәлгә ашыру турында эш бирүче боерыгыннан өземтә;

Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык;

бердәм салым исәбендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычы булмауны яисә Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмауны раслый торган белешмә кәгазе;

эш бирүченең индивидуаль белем бирү проектын гамәлгә ашыру өчен матди-техник һәм хезмәтнең башка шартларын тәэмин итү гарантиясен үз эченә алган хаты.

«Физика-математика профилендәге яшь укытучы», «Педагог – физика-математика түгәрәге җитәкчесе» номинацияләрендә грант алырга теләүчеләр өстәмә рәвештә мотивацияле хат тапшыра.

«Физика-математика профиле укытучысы» номинациясендә грант алырга теләүче өстәмә рәвештә түбәндәге мәгълүмат белән портфолио тапшыра:

грант алырга теләүче тарафыннан әзерләнгән республика, бөтенроссия, халыкара белем алучылар олимпиадаларында җиңүчеләр, приз алучылар турында;

Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы тарафыннан раслана торган олимпиадалар һәм башка интеллектуаль конкурслар, интеллектуаль сәләтләрне, фәнни-тикшеренү, инженерлык-техник, уйлап табу эшчәнлегенә кызыксынуны арттыруга юнәлдерелгән чаралар исемлегенә керә торган конкурсларда грант алырга теләүче тарафыннан әзерләнгән җиңүчеләр, приз алучылар турында;

грант алырга теләүчедә «физика, «математика», «информатика» предметларын тирәнтен өйрәнү программалары буенча белем алган, «физика, «математика», «информатика» предметлары буенча төп дәүләт имтиханы формасында төп гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен узу йомгаклары буенча «бишле» билгесен алган чыгарылыш укучылар турында;

грант алырга теләүчедә укыган, физика, профильле математика, информатика буенча бердәм дәүләт имтиханы формасында урта гомуми белем бирүнең мәгариф программасы буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен узу йомгаклары буенча әлеге предметларның берсеннән 80 һәм аннан күбрәк балл җыйган профильле сыйныфларның чыгарылыш укучылары турында;

грант алырга теләүченең төп дәүләт имтиханын, бердәм дәүләт имтиханын узу йомгаклары буенча «физика», «математика», «информатика» предметларыннан минималь билгеләнгән үтү баллын (бәяне) җыймаган белем алучылары булмау турында;

уку елы дәвамында «Физик-математик алгарыш» проектында катнашучы яшь укытучыларның остазлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында.

Грант алырга теләүче грант номинацияләренең берсеннән генә заявка бирергә мөмкин.

Грант алырга теләүче кәгазь чыганакта заявка формалаштыра һәм аны сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән срокларда операторның урнашу урыны адресы буенча яисә операторга почта аша тапшыра.

Кәгазь чыганактагы заявка составында тапшырылган документлар андагы исемлеккә кертелергә, тегелгән, номерланган һәм грант алырга теләүче тарафыннан таныкланган булырга тиеш.

Тиешле техник мөмкинлекләр булганда, Министрлык карары буенча заявкаларны бирү Россия Федерациясе законнары (шул исәптән шәхси мәгълүматларны саклау өлкәсендә) таләпләрен үтәү шарты белән мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып электрон рәвештә оештырылырга мөмкин. Заявка электрон рәвештә бирелгән очракта, заявка составында тапшырылган документлар заявкага документларның сканерланган күчермәләре рәвешендә теркәлә.

Сайлап алуга бирелгән заявка һәм заявка составындагы документлар грант алырга теләүчеләргә сайлап алу тәмамланганнан соң кире кайтарылмый.

Грант алырга теләүче заявка составында тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җавап бирә.

12. Операторга кергән заявка һәм аның составында тапшырылган документлар операторның урнашу урыны адресы буенча операторга кергән датадан бер эш көне эчендә теркәлә. Заявка почта аша җибәрелгән очракта, заявка оператор тарафыннан оператор почта бүлекчәсеннән аны алган көннән алып бер эш көне эчендә теркәлә. Электрон формада заявка бирелгән очракта, оператор заявканы операторның электрон адресына кергән көннән алып бер эш көне эчендә терки.

Теркәлгән заявкалар оператор тарафыннан конкурс комиссиясенә Министрлык боерыгы белән расланган заявкаларны кабул итү тәмамланган көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча тапшырыла.

13. Заявканы һәм аның составында тапшырылган документларны карап тикшерү Министрлыкның боерыгы белән составы раслана торган конкурс комиссиясе тарафыннан заявкаларны кабул итү срогы тәмамланганнан көннән алып 10 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Конкурс комиссиясе Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, гомуми белем бирү өлкәсендәге белгечләр, педагогика, физика, математика, информатика өлкәсендәге галимнәр, җәмәгатьчелек вәкилләре арасыннан кимендә биш әгъзадан төзелә. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкилләренең саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми составының яртысыннан артмаска тиеш. Конкурс комиссиясе төзелгәндә конкурс комиссиясе рәисе, аның урынбасары һәм секретаре билгеләнә. Конкурс комиссиясе рәисе булмаганда, аның функцияләрен конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

14. Сайлап алуга конкурс комиссиясе тарафыннан Министрлык боерыгы белән расланган бәяләү критерийлары нигезендә заявкаларны, портфолионы, мотивацияле хатны һәм индивидуаль белем бирү проектын бәяләү керә.

Конкурс комиссиясе карары конкурс комиссиясе рәисе, рәис урынбасары һәм секретаре тарафыннан кул куелган конкурс комиссиясе беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

15. Грант алырга теләүчегә сайлап алуда катнашудан баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

әлеге Нигезләмәнең 11 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы булмаган комплектта тапшыру), һәм (яисә) документларында бирелгән мәгълүмат дөрес булмау;

грант алырга теләүченең әлеге Нигезләмәнең 8 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

заявканы һәм (яисә) документларны заявкаларны кабул итү срогы тәмамланган

датадан соң тапшыру.

Грант алырга түләүчегә сайлап алуда катнашырга рөхсәт ителмәгән очракта, конкурс комиссиясе әлеге карар кабул ителгән көннән алып бер эш көне эчендә операторга, заявканы алмау сәбәпләрен күрсәтеп, бу турында хәбәрнамә җибәрә. Заявкалар бирү срогы тәмамланган көннән соң килә торган эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә оператор грант алырга теләүчегә заявкада күрсәтелгән электрон почта адресына, сайлап алуда катнашудан баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, бу хакта хәбәрнамә җибәрә.

14. Әлеге Нигезләмәнең 11 пункты нигезендә сайлап алу йомгаклары буенча конкурс комиссиясе тарафыннан җыелган баллар кими бара торган тәртиптә грант алырга теләүчеләрнең рангларга бүленгән исемлеге төзелә. Сайлап алуда җиңүчеләр дип сайлап алу йомгаклары буенча иң күп балл җыйган, грант аларга теләүчеләрнең рангларга бүленгән исемлегендә түбәндәге номинация буенча урын алган грант алырга теләүчеләр таныла:

«Физика-математика профиле укытучысы» – 1 нче урыннан 100 нче урынга кадәр;

«Физика-математика профилендәге яшь укытучы» – 1 нче урыннан 150 нче урынга кадәр;

«Педагог – физика-математика түгәрәге җитәкчесе» – 1 нче урыннан 100 нче урынга кадәр.

Грант алырга теләүчеләрнең рангларга бүленгән исемлеге конкурс комиссиясе беркетмәсенең аерылгысыз бер өлеше булып тора.

Конкурс комиссиясе беркетмәсе Министрлыкка аңа куелган датадан алып биш эш көне эчендә җибәрелә.

Министрлык конкурс комиссиясе беркетмәсе нигезендә грант бирү турында йә грант бирүдән баш тарту турында карар кабул итә, ул конкурс комиссиясе беркетмәсе кергән көннән алып биш эш көне эчендә Министрлык боерыгы белән раслана.

17. Грант, Министрлык тарафыннан грант бирү турында карар кабул ителгән көннән соң килә торган 30 календарь көннән дә соңга калмыйча, Министрлыкның боерыгы белән расланган форма буенча Министрлык, грант алучы һәм грант алучының эш бирүчесе арасында төзелә торган килешү нигезендә бирелә.

18. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

грант бирү максатлары;

грант күләме;

грантны күчерү сроклары һәм тәртибе;

субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап бирү сроклары һәм тәртибе;

грант бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләре һәм аларга ирешү сроклары;

индивидуаль белем бирү проектын гамәлгә ашыру срогы, әмма иң күбе бер уку елы;

индивидуаль белем бирү проектын гамәлгә ашыру турында хисап бирү сроклары һәм тәртибе;

Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан грант алучының грант бирү шартларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүләрне гамәлгә ашыруга ризалыгы;

грант түләүне туктатып тору, туктату очраклары һәм тәртибе;

грантны кире кайтару очраклары һәм тәртибе;

грантны мәҗбүри түләтү буенча чаралар кабул итү сроклары;

грант алучының әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында билгеләнгән грант бирү шартларын үтәү буенча бурычы;

грант бирү шартларын һәм тәртибен бозган өчен җаваплылык;

грант алучының индивидуаль белем бирү проектын гамәлгә ашыру срогы эчендә эш бирүчедә хезмәт педагогик эшчәнлеген гамәлгә ашыру йөкләмәсе;

грант алучының, эш бирүченең грант бирелгән ел дәвамында грант алучы белән хезмәт мөнәсәбәтләрен туктату датасыннан алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча эш бирүче белән хезмәт мөнәсәбәтен өзү турында Министрлыкка хәбәр итү йөкләмәсе.

19. Грант алучы тарафыннан индивидуаль белем бирү проектын гамәлгә ашыру срогы тәмамланганга кадәр эш бирүче белән хезмәт шартнамәсе өзелгәндә элек түләнгән грант суммасы, эш бирүче белән хезмәт шартнамәсе өзелгән көннән алып өч айдан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы бюджетына тулы күләмдә кайтарылырга тиеш.

Грант алучының хәрби хезмәткәр булып хезмәт иткән, махсус хәрби операциядә катнашкан ире (хатыны) яшәү урынын алмаштыруга бәйле рәвештә, грант алучы тарафыннан индивидуаль белем бирү проектын гамәлгә ашыру срогы тәмамланганга кадәр эш бирүче белән төзелгән хезмәт шартнамәсе өзелгән очракта, шулай ук эш бирүче ябылган очракта, элек түләнгән грант суммасы кире кайтарылмый.

20. Грант алучыларга грант бирү Министрлык тарафыннан Россия кредит оешмаларында ачылган грант алучының шәхси счетларына күчерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

21. Грант алучылар килешү белән билгеләнгән форма буенча һәм срок эчендә грант бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап булып торган индивидуаль белем бирү проектын гамәлгә ашыру турында эш бирүче белән килештерелгән хисапны операторга бирә.

Индивидуаль белем бирү проектын гамәлгә ашыру турында хисапта түбәндәгеләр күрсәтелә:

индивидуаль белем бирү проектын гамәлгә ашыру кысаларында үткәрелгән чараларның педагогик әһәмияте;

индивидуаль белем бирү проектында каралган, эш бирүче тарафыннан ирешү нәтиҗәләре расланган, максатчан күрсәткечләргә ирешүдән гыйбарәт грант алучының педагогик эшчәнлеге нәтиҗәлелеге.

Эш бирүче тарафыннан грант алучының индивидуаль белем бирү проектында каралган максатчан күрсәткечләргә ирешү фактын раслау индивидуаль белем бирү проектын гамәлгә ашыру турындагы хисапның беренче битендә уңъяк югары почмакка «Расланды» грифын кую һәм эш бирүченең җитәкчесе яисә аның вәкаләтле заты имзасын кую юлы белән гамәлгә ашырыла.

22. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары грант алучы тарафыннан грантлар бирү шартлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

23. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр йомгаклары буенча әлеге Нигезләмәдә һәм төзелгән килешүдә билгеләнгән грантлар бирү шартлары һәм тәртибе бозылу факты ачыкланган очракта, грант алучы Министрлыкның язма таләпләрен алган көннән 30 календарь көн эчендә алынган акчаны Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтаруны гамәлгә ашыра.

Әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджеты кеременә ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тартылган очракта, алар Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

24. Грантны нәтиҗәле куллануны, аны бирү шартларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.